Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге Советы

# LVIII-2 НОМЕРЛЫ КАРАР

Олы Елга авылы 2019 елның 13 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2014 елның 09 октябрендәге IX номерлы “Җир салымы турында”карарына үзгәрешләр кертү турында»

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында 15.04.2019 ел, №63-ФЗ «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм «Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 9 статьясына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Олы Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2014 елның 09 октябрендә кабул ителгән «Физик затлар милкенә салым турында» гы IX-1 карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 ноябрендәге X-1 номерлы, 2015 елның 29 маендагы XXIII-1 номерлы, 2017 елның 22 августындагы XXXII-4 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 2 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«Шәхси хуҗалык, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,3% тәшкил итә; »

1.2) 3нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә::

«I һәм II группа инвалидлыкка ия булган инвалидлар, балачактан инвалидлар, инвалид балалары булган гаиләләр,күп балалы гаиләләр,торак фонды, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, яшелчәчелек яки терлекчелек өчен бирелгән җир кишәрлекләренә, шулай ук дача хуҗалыгына, милектәге авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә, даими (сроксыз) яки

гомерлек мирас итеп файдалану өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата; ».

2. Әлеге карар, әлеге карарның 3 пункты үз көченә керүнең башка вакыты билгеләнгән Нигезләмәдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге Советының 2014 елның 09 октябрендәге IX-1 номерлы «Җир салымы турында» карарының 2 пунктындагы 4 абзацына кертелгән үзгәрешләр 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы,Олы Елга авылы , Октябрь урамы, 25 нче йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 нчы йорт; Саескан Тавы авылы, Үзәк урам, 16А йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы" Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районының
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы Ф.А.Садриев

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН РЫБНО-СЛОБОДСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТ БОЛЬШЕЕЛГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1634000235
ОЛЫ ЕЛГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Р 96-2131/02